| | |
|---|---|
| ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2022 с. Шеланга 9

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Яңа Юл поселогында гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Шиланга авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 30 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Яңа Юл поселогы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Юл бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 215 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтүгә риза булырсызмы:

- кече архитектура формалары (таган, тренажер) сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яңа Юл авыл клубында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Яңа Юл бистәсе, Үзәк ур., 17 йорт 11.00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шиланга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров